**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

**423739, Качкын авылы, Үзәк урам, 37в йорты. Тел.3-44-63**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**423739, деревня Качкиново, ул. Центральная, дом 37в,3-44-63**

---

КАРАР
10.05.2021ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№7

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 елның 12 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 12 февралендәге 3 номерлы «Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 бүлегенең 7 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының административ регламентлары проектларын эшләү һәм килештерү дәүләт мәгълүмат системасында һәм (яки) муниципаль мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хезмәтләре реестрын, муниципаль хезмәтләр реестрын электрон рәвештә алып баруны тәэмин итә»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Усы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет житәкчесе З.З.Ахмаев